**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Кәкре Елга авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Кәкре Елга авылы № 72-36 "15" декабрь 2022 ел

Җирле салымнар суммасы өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия ФНСның 2019 елның 02 апрелендәге ММВ-7-8/164@ "Бурычларны һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычны өзү тәртибен һәм түләтүгә өметсез дип танылган документлар исемлеген раслау турында" боерыгы нигезендә

Кәкре Елга авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җирле салымнар суммасы өлешендә (алга таба - бурыч) бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләрне билгеләргә:

- мирас алучы мираска хокуктан баш тарткан очракта, мирас алучы булмаган яисә мирас калдырган көннән алып бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта вафат яисә вафат дип игълан ителгән физик затларның җир салымы һәм милек салымы буенча;

- җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча өч елдан артык бурычны түләтүгә өметсез дип таныган датадан;

- суд приставы - “Башкару эшчәнлеге турында” 2007 елның 02 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 һәм 47 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында билгеләнгән нигезләрдә башкарма документ алучысын кире кайтару турында карарын үтәүче тарафыннан чыгарылган очракта, җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча;

- гамәлдән чыгарылган җирле салымнар һәм җыемнар буенча, реструктуризация режимында һәм бөлгенлек (банкротлык) процедураларында булган салым түләүчеләргә бурычлардан тыш;

- ата-аналары ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән балалар йортларында һәм приютларда тәрбияләнүче балигъ булмаганнарның җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча;

- ЕГРЮЛда мәгълүмат булмаган юридик затларның җир салымы буенча;

- җир салымы буенча юридик затларның аларны түләтү срогы тәмамланганнан соң недоимкага исәпләнгән пенялар буенча бурычлары, алар исәпләгән недоимка булмаганда.

2. Салым түләүченең бурычы исемлеге салым органы тарафыннан әлеге карар нигезендә һәм җирле салымнар суммалары өлешендә салым органы белешмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Бурычлары түләтүгә өметсез дип танылырга тиешле физик затлар исемлеге, җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләп бетерүгә ышанычсыз дип тануның шартларын раслаучы документлар кушып, салым органы тарафыннан Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге башкарма комитетына килештерү өчен бирелә.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- 2014 елның 24 ноябрендәге 114 номерлы «Әлеге салымнар буенча недоимка һәм штрафлар буенча бурыч түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында»;

- 2015 елның 05 ноябрендәге 15 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең «Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 114 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында».

- 2018 елның 24 ноябрендәге 13 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең «Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр турында» 2014 елның 05 ноябрендәге 15 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында».

5. Әлеге карар 2023 елның 01 гыйнварындагы үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.М.Мөхәмәтҗанов